СОВЕТ
СРЕДНЕКОРСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Молодежная, д.13, д. Средняя Корса,
Арский муниципальный район, 422024

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА КУРСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Яшьләр ур, 13 йорт, Урта Курса авылы,
Арча муниципаль районы, 422024

Тел. (84366) 53-4-32, факс (84366) 53-4-32. E-mail: Skor.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

**КАРАРЫ**

**19 октябрь 2020 ел** **№ 7**

**Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге Сарай-Чокырча авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Урта Курса авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге Сарай-Чокырча авылында Сарай-Чокырча авылы, М.Җәлил урамы, 23 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2020 елның 13 ноябренә 13 сәгать 00 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге Сарай-Чокырча авылында Сарай-Чокырча авылы, Зур Кызыл урамы, 18а адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2020 елның 13 ноябренә 14 сәгать 00 минутта халык җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге Сарай-Чокырча авылында Сарай-Чокырча авылы, Зур Кызыл урамы, 18а адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2020 елның 13 ноябренә 15 сәгать 00 минутта халык җыенының өченче этабын билгеләргә.
4. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга.

   1нче этап: Г. Камал урамында яшәүчеләр
   2нче этап: М.Җәлил урамында яшәүчеләр
   3нче этап: Зур Кызыл урамында яшәүчеләр.
5. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2021 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге Сарай-Чокырча авылы территориясендә

теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 500 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 80 яшьтән узган гражданнардан, тумыштан булган инвалидлардан тыш, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- зират коймасын ремонтлау өчен материаллар сатып алу һәм ремонтлау;
- 1 данә янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру;
- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру, Г. Камал урамында 5 линия сузу;
- Сарай-Чокырча авылында Зур Кызыл ур., 24а йортыннан алып М. Җәлил ур., 26 йортка кадәр тышкы су үткәргеч торбалар салу.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

"ӘЙЕ" "КАРШЫ"

3. Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге Сарай-Чокырча авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Урта Курса авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Сарай-Чокырча авылы, Зур Кызыл урамы, 21 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Урта Курса авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Вафина